| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь, 2025 ел Кукмара ш. № __

Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен тәңгәлләштерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге халкының Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен тәңгәлләштерү турындагы мәсьәләне тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында, гавами тыңлаулар уздыру юлы белән

КАРАР БИРӘМ:

1. Кукмара муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен тәңгәлләштерү турында» 2025 елның 7 ноябрендәге 20 номерлы карарында белдерелгән инициативаны карау турында гавами тыңлауларны 1 нче кушымта нигезендә 2025 елның 5 декабренә билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны уздыру урыны итеп Кукмара муниципаль районы Советы утырышлар залын билгеләргә, адресы: Татарстан Республикасы, Кукмара шәһәре, Ленин урамы, 13 йорт. Уздыру вакыты: 14 сәг. 00 мин.

3. Гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итүне һәм проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен 2 нче Кушымта нигезендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (https://kukmor.tatarstan.ru) 2025 елның 15 ноябренә кадәр урнаштырырга.


2025 елның 8 декабренә кадәр гавами тыңлаулар йомгакларын Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (https://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Гавами тыңлаулар уздыру комиссиясе составын 3 нче кушымта

нигезендә васларга.
5. Билгеләргә:
5.1. гавами тыңлауларны оештыручы – гавами тыңлауларны уздыру комиссиясе;
5.2. проектның электрон версиясе һәм аңа мәгълүмати материаллар Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган.
6. Гавами тыңлаулар уздыру комиссиясе:
6.1. әлеге карар белән билгеләнгән сроклар нигезендә гавами тыңлаулар әзерләүне тәэмин итә;
6.2. гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерли һәм рәсмиләштерә.
7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кукмара муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Н. Гаяновага йөкләргә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 10 ноябрендәге ___ номерлы карарына 1 нче кушымта



Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 10 ноябрендәге ___ номерлы карарына 2 нче кушымта

Проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе

1. Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә тәңгәлләштерү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәрне 1 нче кушымта нигезендә Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Инфраструктура үсеше бүлегенә түбәндәге адрес буенча кертелә: Кукмара ш., Ленин ур., 13 й., 310 кабинет яисә 2-80-56 телефоны буенча язма рәвештә гавами тыңлаулар тамгасы белән кертелә.

2. Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керә торган Мәмәшир авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә тәңгәлләштерү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәрне эш көннәрендә 2025 елның 4 декабренә кадәр 8-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Кукмара шәһәре, Ленин урамы, 13 йорт, 310 кабинет яисә почта аша ( конвертта «гавами тыңлаулар» тамгасы белән) җибәрелә яисә 2-80-56 телефоны буенча.

4. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан теркәлә.

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 10 ноябрендәге ___ номерлы карарына 3 нче кушымта

Гавами тыңлаулар уздыру комиссиясе СОСТАВЫ:

| ФИА | Функцияләре | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| Гаянова Р.Н. | гавами тыңлауларны үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе |
| Ризванов Н.Р. | гавами тыңлауларны әзерләү, эксперт | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Хөснетдинов Рушан Минерамил улы | беркетмә язу | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы |
| Комиссиия әгъзалары: | | |
| Габидуллин И.И. | депутатларга хәбәр итү | Кукмара муниципаль районы Советы Аппаратының Оештыру бүлеге башлыгы |
| Гарифуллин А.Х. | гомуми мәсьәләләр | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Закиров И.Г. | җир, категория, милекчеләр | Кукмара муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Әхмәтшина А.М. | социаль блок (медицина, мәдәният, мәгариф) | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| Хәлиуллин Рафак Шамил улы | авыл хуҗалыгы | Кукмара муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы |
| Сабирова М.Ф. | халыкка хәбәр итү | Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре Советының баш белгече |